| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕКАЧКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЕЛАБУЖСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЧЫК АВЫЛЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Олы Качык авылы** **КАРАР**

№ 2 5 декабрь, 2019 ел

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Качык торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Олы Качык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставның 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Качык торак пунктының Совет урамында урнашкан 1-24 йортлар буенча 2019 елның 20 декабренә 14 сәгатькә Совет урамы, 18 нче йортта үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Качык торак пунктының Совет урамында урнашкан 25-60 йортлар буенча 2019 елның 20 декабренә 18 сәгатькә Совет урамы, 42 нче йортта үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Качык торак пунктының Якты урамы буенча 2019 елның 20 декабренә 19 сәгатькә Якты урамы, 3 нче йортта үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өчнче этабын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Качык торак пунктының Мәктәп урамы буенча 2019 елның 20 декабренә 20 сәгатькә Мәктәп урамы, 11 нче йортта үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Качык торак пунктында яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Гражданнар җыенына тәкъдим ителгән сорауларны расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Качыкторак пункты чикләрендә урнашкан даими яшәүче гражданнар һәм 18 яшькә җиткән кешеләр өчен 200 (ике йөз) сум күләмендә, гомуми авырудагы инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарына, күпбалалы гаиләләр, югары һәм урта-махсус (урта-һөнәри) уку йортларында белем алучы студентлар өчен 100 (йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмиияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкру буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?»

- Алабуга муниципаль районы Олы Качык авыл җирлегенең Олы Качык торак пунктында су белән тәэмин итү системасына су коелары урнаштыру.
- “ӘЙЕ” - “ЮК”

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җитәкче А.А. Голованов